Республика Татарстан

Исполнительный комитет
Менделеевского
муниципального района

Татарстан Республикасы

Менделеевск муниципаль
районы
башкарма комитеты

ПОСТАНОВЛЕНИЕ

КАРАР

17.03.2023 ел

Менделеевск ш.

№154

Мәҗбүри эш төрләрен билгеләү
һәм мәҗбүри эш рәвешендә
административ җәза үтәлә торган
оешмалар исемлеген билгеләү турында

Административ хокук бозулар турында Россия Федерациясе кодексының 3.13 һәм 32.13 статьялары нигезендә Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районы башкарма комитеты мәҗбүри эшләр рәвешендәге административ җәза билгеләнгән затларны төзәтү, аларда нормаларга, җәмгыять кагыйдәләренә, иҗтимагый файдалы хезмәткә карата хөрмәт уяту максатларында

КАРАР ЧЫГАРДЫ:

1. Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районы территориясендә мәҗбүри эшләр рәвешендәге административ җәза үтәлә торган оешмалар исемлеген һәм Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районы территориясендә административ хокук бозган физик затлар тарафыннан башкарыла торган мәҗбүри эшләр төрләрен кушымта нигезендә билгеләргә.

2. Әлеге карарның кушымтасында күрсәтелгән оешмалар җитәкчеләренә мәҗбүри эшләр рәвешендә җәза үтәү мәсьәләләре буенча суд приставлары хезмәтләре белән хезмәттәшлек өчен җаваплы хезмәткәрләрне билгеләп куярга.

3. Суд приставлары федераль хезмәте Татарстан Республикасы буенча идарәсенең Менделеевск районы буенча суд приставлары бүлегенә мәҗбүри эшләр рәвешендәге административ җәзалар үтәүче оешмаларга хокукый һәм методик ярдәм күрсәтергә тәкъдим итәргә.

4. Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районы Башкарма комитетының «Мәҗбүри эшләр төрләрен һәм мәҗбүри эшләр рәвешендәге административ җәзаларны үтәтү оешмалары исемлеген билгеләү турында» 2022 елның 22 августындагы 501 номерлы карарын үз көчләрен югалткан дип танырга.

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат порталында http//pravo.tatarstan.ru бастырып чыгарырга.

5. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең шәһәр хуҗалыгы буенча урынбасарына йөкләргә.

Җитәкче Р.Р.Искәндәров

Татарстан Республикасы
Менделеевск муниципаль районы
Башкарма комитетының
2023 елның 17 мартындагы 154 номерлы
карарына кушымта

Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районы территориясендә мәҗбүри эшләр рәвешендәге административ җәза үтәлә торган оешмалар һәм Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районы территориясендә административ хокук бозган физик затлар тарафыннан башкарыла торган мәҗбүри эшләр төрләре исемлеге

| Оешманың исеме | Адресы | Салым түләүченең тәңгәлләштерү номеры (ИНН) | Эшләр төрләре |
|---|---|---|---|
| «Менделеевск муниципаль районының торак-коммуналь хуҗалык идарәсе» муниципаль унитар предприятиесе | 423650, ТР, Менделеевск ш., Фомин ур., 19 й. | 1627009678 | Территорияне җыештыру, очраклы чүп-чар җыю, кардан чистарту,, чүп-чарны төяү һәм бушату |
| «Төзекләндерү идарәсе» муниципаль унитар предприятиесе | 423650, ТР, Менделеевск ш., Фомин ур., 19 й. | 1627009540 | Территорияне җыештыру, очраклы чүп-чар җыю, кардан чистарту,, чүп-чарны төяү һәм бушату, урамнарны себерү |
| Татарстан Республикасы «Менделеевск муниципаль районының административ - хуҗалык учреждениесе» муниципаль бюджет учреждениесе | 423650, ТР, Менделеевск ш., Фомин ур., 19 й. | 1627016851 | Территорияне җыештыру, очраклы чүп-чар җыю, кардан чистарту,, чүп-чарны төяү һәм бушату |
| Татарстан Республикасы Менделеевск суд районы буенча 1 нче суд участогы | 423652, ТР, Менделеевск ш., Максим Горький ур., 3а й. | 1654003139 | Территорияне җыештыру, очраклы чүп-чар җыю, кардан чистарту,, чүп-чарны төяү һәм бушату |
| Татарстан | 423652, ТР, | 1654003139 | Территорияне |

| | | | |
|---|---|---|---|
| Республикасы Менделеевск суд районы буенча 2 нче суд участогы | Менделеевск ш., Максим Горький ур., 3а й. | | җыештыру, очраклы чүп-чар җыю, кардан чистарту,, чүп-чарны төяү һәм бушату |